ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
пр. Мира 12, г. Елабуга, 423603

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тынычлык пр.12, Алабугашәһәре, 423603

тел.(85557) 30832, факс.(85557)34211, E-mail: rik_emr@mail.ru, сайт: городелабуга.рф

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1769 29.11.2019

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендәге «2017 - 2019 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 1714 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Алабуга муниципаль районында муниципаль программаларны эшләү һәм раслау тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 декабрендәге «2017 - 2019 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында» 1714 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2017-2022 елларга Алабуга муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын раслау турында».

2. «2017 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасын яңа редакциядә расларга.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында 2017-2022 елларга янгын куркынычсызлыгы» муниципаль программасы чараларын үтәү өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Р. М. Нуриев